**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

**2023елның 23 августы** **59 номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022елның 12 декабрендәге 23 номерлы Габишев авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 12 декабрендәге 23 номерлы Габишев авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә;

29 статьяның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-Федераль казначылык тарафыннан артык бүленгән суммаларны, артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнарны, җыемнарны һәм башка түләүләрне кире кайтаруны (исәпләүне, төгәлләштерүне) гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчаларны, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне исәпкә алу һәм аларны бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен тиешле казначылык счетларына тиешле бюджетларның бердәй счетларыннан арттырылган суммаларны һәм процентларны вакытында башкармаган өчен процентлар күчерү;

29 статьяның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-әлеге Кодекста, Россия Федерациясе субъектлары бюджеты һәм башка законнары турындагы законда (карар) һәм әлеге Кодекс нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән, агымдагы финанс елында гамәлдә булган нормативлар буенча бүленә торган Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка керемнәр бүлүдән кергән керемнәрне исәпкә алу һәм

аларны бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларыннан күчерү;

13 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Бюджетлар проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәте таләпләрен) билгеләүче Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Җыенына юлламасы нигезләмәләренә;

Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча иҗтимагый хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләүче документларга;

- Россия Федерациясенең Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләренә (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисади үсеш фаразларына;

- озак вакытлы чорга бюджет фаразына (бюджет прогнозы проекты, бюджет прогнозы үзгәрешләре проекты);

- дәүләт (муниципаль) программаларына (дәүләт (муниципаль) программалары проектларында, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр кертү проектларында).

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев җирлеге Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Габишев**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **М.Ф.Миндубаев**